КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 31 июль г.Казань № 639

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасында санитар-эпидемиологик хәлне һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу үзенчәлекләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 15 июль, 591 нче; 2020 ел, 25 июль, 625 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

а) бүлмәләрдә, шул исәптән сәүдә һәм сәүдә-күңел ачу үзәкләрендә (комплексларында), аттракционнарда һәм гражданнар күпләп йөри торган башка урыннарда ял итү, күңел ачу, тамаша, мәдәни, физкультура, спорт, күргәзмә, агарту, реклама һәм башка шундый чаралар үткәрү рөхсәт ителми.

Әлеге чикләү музейлар, китапханәләр эшенә, шулай ук индивидуаль яки иң күбе 5 кешедән, ә экскурсия эшен алып бару өчен махсуслаштырылган радиоҗиһаз булганда иң күбе 10 кешедән торган төркемнәргә экскурсия хезмәтләре күрсәтүгә кагылмый;

б) түбәндәгеләр рөхсәт ителә:

дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу шартларында профилактика чараларының үтәлешен тәэмин итә торган формада чаралар оештыру һәм үткәрү;

чара үткәргәнгә кадәр кимендә җиде көн кала Кулланучылар хокукларын саклау һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенә алдан язма хәбәрнамә җибәрү шарты белән берьюлы иң күбе 50 кеше катнашында ачык мәйданчыкларда ял, күңел ачу, тамаша, мәдәни, физкультура, спорт, күргәзмә, агарту, реклама һәм башка шундый чаралар оештыру һәм үткәрү;

ачык һавада аттракционнар эшләү;

ачык һавада урнашкан вольерлар өлешендәге зоопарклар эшләү.»;

4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. 2020 елның 26 мартыннан санитар-эпидемиологик хәл яхшырганга кадәр кинотеатрлар (кинозаллар), төнге клублар (дискотекалар), балалар уен бүлмәләре, балалар күңел ачу үзәкләре һәм башка күңел ачу оешмалары эшчәнлеген (чара үткәргәнгә кадәр кимендә җиде көн кала Кулланучылар хокукларын саклау һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенә алдан язма хәбәрнамә җибәрү шарты белән берьюлы иң күбе 50 кеше катнашында ачык мәйданчыкларда ял, күңел ачу, тамаша, мәдәни, физкультура, спорт, күргәзмә, агарту, реклама һәм башка шундый чаралар оештырудан һәм үткәрүдән тыш) туктатырга.».

2. Бу карар 2020 елның 3 августыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин